# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге составына керүче Мельничная авылы торак пунктында

2023 елның 27 октябре                                        № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35нче маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Мельничная торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. 2024 елда Балтач районы Чепья авыл җирлегенең Мельничная авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән; 50 процент күләмендә ташлама каралган - 1 төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлардан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш; 1100 сум күләмендә үзара салым кертү күздә тотыла.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Мельничная авылы Молодежная урамы юл-урам челтәрен һәм юлларга асфальт-бетон җәюне норматив хәлгә китерү
- Янгынга каршы гидрант өчен бер комплектлаучы әйбер сатып алу.

3. Җыен нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә. http://pravo.tatarstan.ru> Балтач муниципаль районы сайтында baltasi.tatar.ru к

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Чепья авыл җирлеге башлыгы                                        А. Г. Нотфуллин